**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 23 маендагы 1601 номерлы карары**

## Казан шәһәренең Яңа Савин районында ачык сервитут билгеләү турында

1. Әлеге карарга 1, 2 номерлы кушымталары нигезендә ачык сервитут билгеләргә:

1.1. билгеләнә торган ачык сервитут характеристикасы:

- йогынты ясала торган өлкә мәйданы – 120366 кв.м;

- хокуклар чикләнә торган җир кишәрлекләренең кадастр номерлары – 16:50:000000:154, 16:50:000000:36915, 16:50:000000:928, 16:50:110603:3241, 16:50:040101:668, 16:50:040101:666, 16:50:040101:670, 16:50:040101:10, 16:50:000000:8455, 16:50:110603:12158, 16:50:000000:34268, 16:50:040101:696, 16:50:110603:12, 16:50:000000:939, 16:50:110603:12163, 16:50:000000:5567;

- урнашу урыны: Казан шәһәре, Яңа Савин районы;

- билгеләү максаты: җәяү һәм транспортта узуны тәэмин итү өчен;

- билгеләү вакыты: 5 ел;

1.2. гариза бирүче: «БРИКС махсуслаштырылган төзү оешмасы» ҖЧҖ;

1.3. билгеләү өчен нигезләр: гариза бирүче мөрәҗәгате, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль закон, Россия Федерациясе Җир кодексының 23 статьясы.

2. Әлеге карарга 1 һәм 2 номерлы кушымталарда күрсәтелгән җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төре нигезендә файдалану мөмкин булмаячак яки сизелерлек кыенлашачак вакыт әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән ачык сервитут вакытына туры килә дип билгеләргә.

3. «Казанны үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесенә әлеге карарга 1, 2 номерлы кушымталар нигезендә чикләрдә ачык сервитутның йогынты ясау өлкәсе турында тиешле мәгълүмат кертү һәм ачык сервитутны дәүләт теркәвенә алу өчен Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә мөрәҗәгать итүне йөкләргә.

4. Әлеге карарны, 2 номерлы кушымтасыннан кала (хезмәт урынында файдалана торган материал), «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» чөлтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.


6. Җир кишәрлекләреннән алга таба файдаланганда, гариза бирүчегә Россия Федерациясе Мәдәният министрлыгының 2023 елның 11 маендагы 1311 номерлы «Бөтендөнья мирасы исемлегенә кертелгән федераль әһәмияткә ия «Казан кремле ансамбле», XV гасыр – XX гасырның беренче чиреге (Татарстан Республикасы (Татарстан) мәдәни мирас объектын саклау зоналары чикләрен, җирләрдән файдалануның махсус режимнарын һәм әлеге зоналар территорияләре чикләрендә шәһәр төзелеше регламентларына карата таләпләрне раслау турында»гы әмере нигезендә чикләүләрне үтәргә тәкъдим итәргә, аның буенча хокуклар чикләнә торган җир кишәрлекләре ЗРЗ(Б)-30, ЗРЗ(Б)-32, ЗРЗ(Б)-33, ЗРЗ(Б)-45, ЗРЗ(В)-3 төзелешне һәм хуҗалык эшчәнлеген җайга салу зонасында урнашкан.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Р.Р.Шәфигуллинга йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2025 елның 23 маендагы
1601 номерлы карары
белән расланган
1 номерлы кушымта

## Ачык сервитут йогынты ясый торган өлкә чикләре




| | |
|---|---|
| Масштаб: 1:7000<br>Координаталар системасы: МСК-16 | |
| Шартлы билгеләр: | |
| 1 | Яңа ясалган характерлы нокта |
| | Ачык сервитутлар (Проектлана торган) |
| | Җир кишәрлекләре |
| 16:50:040101, 16:50:110511, 16:50:110603 | кадастр кварталы |

| | |
|---|---|
| 16:50:000000:154, 16:50:000000:36915, 16:50:000000:928, 16:50:110603:3241, 16:50:040101:668, 16:50:040101:666, 16:50:040101:670, 16:50:040101:10, 16:50:000000:8455, 16:50:110603:12158, 16:50:000000:34268, 16:50:040101:696, 16:50:110603:12, 16:50:000000:939, 16:50:110603:12163, 16:50:000000:5567 | хокуклар чикләнә торган җир кишәрлегенең кадастр номеры |

__________________________________